КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 15 май г.Казань № 395

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында» 2010 ел, 18 ноябрь, 906 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турындагы бертип нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында» 2010 ел, 18 ноябрь, 906 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 15 октябрь, 856 нчы; 2013 ел, 24 октябрь, 793 нче; 2014 ел, 20 сентябрь, 669 нчы; 2015 ел, 14 май, 341 нче; 2015 ел, 5 сентябрь, 643 нче; 2015 ел, 17 ноябрь, 862 нче; 2017 ел, 10 октябрь, 781 нче; 2018 ел, 24 август, 708 нче; 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турындагы бертип нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«җәмгыятьтә коррупцияле тотышка карата түземсезлекне формалаштыру.»;

3.7 нче пунктның унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«алар чит ил дәүләте гражданлыгын (гражданлыгында булуны) алу;»;

5.12 нче пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин